Республика Татарстан

ГЛАВА ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423950, п.г.т.Уруссу ул.Пушкина, 38
тел.: (85593) 2-80-13
факс: (85593) 2-62-20

Татарстан Республикасы

ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

423950, Урыссу ш.т.б. Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-80-13
факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**“ 28 ” 02 2023г.** **№ 15**

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы территориясендә
кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү
буенча координация советын төзү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июнендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2020 елның 28 апрелендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү буенча координация советы төзергә.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү буенча координация советы турында нигезләмәне (1 нче кушымта);

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү буенча координация советы составын (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Башлыгы А.Ә. Шәфигуллин

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
башлыгының
________ 20____ №___ карарына

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү буенча координация советы турында нигезләмә

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү буенча координация советы (алга таба - координация советы) Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июнендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы (алга таба - муниципаль берәмлек) территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү чараларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм үтәлешен тикшереп тору һәм кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә сәясәт формалаштырганда килешенгән карарлар эшләү буенча кече һәм урта эшкуарлык субъектлары мәнфәгатьләрен белдерүче җирле үзидарә органнары, коммерцияле булмаган оешмалар эшчәнлеген координацияләү максатыннан төзелде.

2. Координация советы кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерүгә юнәлдерелгән чараларны эшләү һәм гамәлгә ашыру буенча киңәшмә органы булып тора.

3. Координация советы:

- кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүне җайга сала торган муниципаль берәмлекнең муниципаль хокукый актлары проектларына иҗтимагый экспертиза үткәрүдә катнаша;

- кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә муниципаль сәясәтне эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнаша;

- муниципаль әһәмияткә ия һәм кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә муниципаль сәясәтне гамәлгә ашыруга юнәлтелгән инициативаларны күрсәтә һәм хуплый;

- гражданнарны, иҗтимагый берләшмәләрне һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләрен эшкуарлык эшчәнлегенә гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыруга кагылышлы мәсьәләләр буенча фикер алышуга һәм шушы мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр эшләүгә җәлеп итә;

- муниципаль берәмлектә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә комачаулаучы административ киртәләрне бетерү буенча чаралар комплексын эшләүдә катнаша;

- кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм өлкәсендә муниципалитетара, төбәкара һәм халыкара тәҗрибә алмашуга ярдәм итә.

4. Координация советы җирле үзидарә органнарыннан, профсоюзлардан, коммерциягә карамаган кече эшкуарлык субъектлары, эшмәкәрләр берләшмәләре мәнфәгатьләрен чагылдыручы оешмалардан, шулай ук муниципаль берәмлекнең кече һәм урта эшмәкәрлек проблемалары буенча эшләрнең торышы турында кече һәм урта эшмәкәрлек эшен җайга сала торган башка структуралардан кирәкле материалларны һәм документларны соратып

алырга хокуклы.

5. Координация советы утырышларына, киңәш бирү тавышы хокукы белән, иҗтимагый оешмалар вәкилләре, шулай ук уку йортлары җитәкчеләре, белгечләр, галимнәр, эшмәкәрләр, экспертлар, консультантлар чакырылырга мөмкин.

6. Координация советы комиссияләр төзи, сөйләшүләр оештыру, экспертизалар үткәрү, предприятиеләргә күчмә утырышлар үткәрү һ. б. өчен үз составыннан һәм җәлеп ителгән белгечләр арасыннан эшче төркемнәр төзи ала.

7. Координация советы җәмәгатьчелеккә үз эшчәнлеге турында хәбәр итә. Аның утырышларында массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре дә катнашырга мөмкин.

8. Координация советы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башлыгы тарафыннан аны булдыру һәм аның турында Нигезләмәне раслау турында карар кабул ителгәннән соң төзелгән дип санала. Координация советының персональ составы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башлыгы Карары белән раслана.

9. Координация советы рәисе булып Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башлыгы тора, килешү буенча рәисе урынбасары булып - Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе.

10. Координация советы утырышы, әгәр дә анда аның составының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, тагын бер тавыш булса, тулы хокуклы була.

11. Координацион совет утырышлары, уздыру кирәк булган саен үткәрелә, ләкин ярты елга бер тапкырдан да ким түгел.

12. Рәис яки, ул булмаганда, - координация советы рәисе урынбасары:

- анда ул (алар) рәислек иткән совет утырышларында мәсьәләләрне карауны оештыралар, совет утырышлары беркетмәләрен имзалыйлар;
- советта кабул ителгән карарларның үтәлешен тикшереп торуны тәэмин итәләр.

13. Координацион совет секретаре:

- эшләрне алып баруны, исәпкә алуны һәм саклауны гамәлгә ашыра;
- беркетмәләр җибәрүне тәэмин итә;
- координация советы эшчәнлеге өчен оештыру-техник чаралар комплексын (планлаштыру, катнашучыларны чакыру, беркетү, язышу һ.б.) башкара;
- Совет утырышлары беркетмәләренә кул куя.

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
башлыгының
________ 20____ №___ карарына

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү буенча координация советы составы

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Шәфигуллин Аяз Әдип улы | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башлыгы, координация советы рәисе |
| 2. | Самонина Светлана Петровна | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, координация советы рәисе урынбасары |
| 3. | Гыйбадуллина Зөлфия Закуан кызы | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары, координация советы секретаре |
| | Координация советы әгъзалары: | |
| 4. | Әхмәдышин Азат Фәнис улы | Хосусый эшмәкәр |
| 5. | Борисов Андрей Владимирович | Ютазы муниципаль районында Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы |
| 6. | Галиев Илгиз Әнвәр улы | Хосусый эшмәкәр |
| 7. | Исхаков Эльдар Марат улы | «Тапарт» ОЭМЗ ҖЧҖ директоры |
| 8. | Кулиева Эльвира Венеровна | Хосусый эшмәкәр |
| 9. | Ляндов Борис Германович | «Горизонт» ҖЧҖ директоры урынбасары |
| 10. | Магамедова Айгөл Миңневәли кызы | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге начальнигы |
| 11. | Мөхәммәтова Руфия Габделмәҗит кызы | Ютазы муниципаль районының финанс-бюджет палатасы рәисе |
| 12. | Низамиев Айрат Мәсгут улы | Хосусый эшмәкәр |
| 13. | Смоленцев Андрей Иванович | Хосусый эшмәкәр |

| | | |
|---|---|---|
| 14. | Тришин Дмитрий Александрович | Хосусый эшмәкәр |
| 15. | Фәйсханов Раушан Камил улы | «АКСКиМ» ҖЧҖ директоры урынбасары |
| 16. | Хөббәтова Алинә Марат кызы | Ютазы муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе |
| 17. | Шәфигуллин Гаяз Гали улы | «Транспорт» ҖЧҖ директоры |